**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясен гамәлгә кую турында**

Татарстан Республикасында театр сәнгатен үстерү һәм Марсель Сәлимҗанов исемен мәңгеләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясен гамәлгә куярга.

2. Ике елга бер тапкыр һәрберсе ике йөз мең сум күләмендә Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге өч республика премиясе бирелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе турында нигезләмәне эшләргә һәм расларга, шулай ук әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка чаралар күрергә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Фән һәм техника, мәгариф, мәдәният, әдәбият һәм сәнгать, массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә күренекле казанышларга ирешкән өчен, салым түләүчеләр тарафыннан алына торган, салым салынырга тиеш булмаган суммалы бүләкләр исемлеген раслау турында» 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-651 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 22 сентябрендәге ПУ-913 номерлы һәм 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1014 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган фән һәм техника, мәгариф, мәдәният, әдәбият һәм сәнгать, массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә күренекле казанышларга ирешкән өчен, салым түләүчеләр тарафыннан алына торган, салым салынырга тиеш булмаган суммалы бүләкләр исемлегенә, түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«7. Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе.».

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2014 ел, 07 ноябрь
№ ПУ-1019